**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«6» апрель 2015 ел № 36/6

**«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 20 декабрендәге 33/3 номерлы Тукай муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 22 декабрендәге 431-ФЗ Федераль законның 7 статьясы, муниципаль берәмлек уставы нигезендә, Тукай районы прокуратурасының 2015 елның 2 мартындагы 02-08-02 номерлы протесты нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 20 декабрендәге 33/3 номерлы Тукай муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәнең 6 статьясы «в» өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«в) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары,

шулай ук хатынының (иренең) һәм (яисә) балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, белешмәләр бирү елыннан алдагы календарь ел дәвамында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артыграк булса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында.»

1.2. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәнең 13 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә:

«13. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча алыш-биреш эшләре башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, шулай ук календарь ел дәвамында ул, аның хатыны (ире) һәм (яки) балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында Тукай районы Советының 22.02.2011 № 3/14 карары белән билгеләнгән тәртиптә, ә бу белешмәләр «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында булмаган очракта, алар запрослары буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.».

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе — В.Г. Хаҗиев